**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 26 июнь № 464

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларын үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2007/2008 – 2014/2015 уку елларында Татарстан Республикасында Россия Федерациясе халык хуҗалыгы оешмалары өчен идарә итүче кадрлар әзерләү буенча дәүләт планын тормышка ашыру чаралары турында» 2008 ел, 15 декабрь, 887 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 12 март, 134 нче; 2011 ел, 13 май, 380 нче; 2012 ел, 29 февраль, 179 нчы; 2012 ел, 7 август, 671 нче; 2012 ел, 10 август, 678 нче; 2012 ел, 5 октябрь, 829 нчы; 2013 ел, 12 сентябрь, 650 нче; 2014 ел, 7 июль, 458 нче, 2015 ел, 10 апрель, 236 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Россия Федерациясе халык хуҗалыгы оешмалары өчен идарә итүче кадрлар әзерләүне оештыру буенча Татарстан төбәк комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составына Раил Рузәл улы Гәрәевне – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – башкарма хакимият органнары хезмәттәшлеген яраштыру идарәсе башлыгын кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2010 ел, 21 октябрь, 834 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 3 февраль, 69 нчы; 2011 ел, 17 март, 199 нчы; 2012 ел, 31 август, 741 нче, 2014 ел, 24 декабрь, 1019 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы коллегиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

коллегия составыннан А.Р.Хәйруллинны чыгарырга;

коллегия составына Ренат Вәгыйз улы Гәйнетдиновны – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгын кертергә;

Альберт Илдар улы Нәфыйгин вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча)».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Конкуренцияне үстерүгә булышлык күрсәтү буенча республика комиссиясе турында» 2014 ел, 24 июнь, 432 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 24 декабрь, 1019 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Конкуренцияне үстерүгә булышлык күрсәтү буенча республика комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Рөстәм Рәфкать улы Сибгатуллин вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары – эшмәкәрлекне үстерү департаменты директоры».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 22 октябрь, б-1710 нчы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 30 декабрь, б-2501 нче; 2013 ел, 9 февраль, б-165 нче; 2014 ел, 30 май, б-1014 нче; 2014 ел, 26 сентябрь, б-1923 нче боерыклары белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 24 декабрь, 1019 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында табыш күләмнәрен киметүгә комплекслы анализ үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Ведомствоара эшче төркем составыннан А.И.Нәфыйгинны, С.С.Сираҗиеваны чыгарырга;

Ведомствоара эшче төркем составына Ренат Вәгыйз улы Гәйнетдиновны – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгын кертергә;

Олег Владимирович Пелевин вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары, эшче төркем җитәкчесе урынбасары».

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 18 август, б-1376 нчы боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 май, б-763 нче; 2014 ел, 12 май, б-829 нчы боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 24 декабрь, 1019 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразларын формалаштыру буенча ведомствоара эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Ведомствоара эшче төркем составыннан А.И.Нәфыйгинны, С.С.Сираҗиеваны чыгарырга;

Ведомствоара эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

Ренат Вәгыйз улы Гәйнетдиновны – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгын;

Олег Владимирович Пелевинны – Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасарын.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарларын көчен югалткан дип таныруга:

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең социаль әһәмиятле проектлары конкурсын үткәрү турында» 2011 ел, 9 август, 648 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең социаль әһәмиятле проектлары конкурсын үткәрү турында» 2011 ел, 09 август, 648 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең социаль әһәмиятле проектлары конкурсы турында нигезләмәгә өстәмә кертү турында» 2011 ел, 10 август, 651 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең социаль әһәмияткә ия булган проектлары конкурсын үткәрү турында» 2011 ел, 9 август, 648 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең социаль әһәмияткә ия булган проектлары конкурсы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2011 ел, 29 август, 727 нче;

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) халык социаль проектлары конкурсын үткәрү турында» 2014 ел, 16 июнь, 416 нчы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\464.doc